
XIX-XX йөз башы татар гаиләсе

(Метрика язмалары мисалында)

Бу мәкалә XIX-XX йөз башында татар гаиләсе институты торышын чагылдырган чыганакка — шул заман метрика язмаларына таянып язылды. Әлеге мөһим һәм зур темага мөрәҗәгать иткәндә бу төр тарихи чыганакларга таянуыбыз бер дә очраклы түгел, чөнки метрика документлары кешенең тууыннан алып соңгы көннәренә кадәр гомернең иң төп этапларын билгелиләр. Һәр мәхәлләдә туу, никахлашу, талак ителү һәм вафат булу фактларын мулла метрика дәфтәрләрендә язып барган. Бу вазифаларны хәзерге вакытта гражданлык халәтен теркәүче җирле үзидарә бүлекләре башкара. Метрика документлары субъектив фикерләрдән тулысынча диярлек азат, чөнки алар теркәлгән фактлардан гына гыйбарәт. Алардагы мәгълүмат иң объектив тарихи чыганаклардан берсе булып санала. Гомумән, метрика язмалары демография мәсьәләләрен өйрәнү өчен бәяләп бетергесез әһәмияткә ия.

Документлардан күренгәнчә, 100-150 ел элек татар гаиләсе шактый ишле булган. Ул заман өчен гаиләдә 7-8 бала булу — гадәти күренеш. Бу очракта сүзебез татар авыллары турында бара; шәһәрдә бу хәлнең бераз башкачарак булуы да ихтимал. Хатын-кыз үз гомерендә, хәтта, 12-15 бала дөньяга китергән, ләкин аларның күбесе балачагында ук шул заманның күпсанлы йогышлы авыруларыннан вафат булган. Мисал итеп, атаклы шәхесләребез гаиләләрен дә китерә алабыз. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның әнисе Бибикамәрия Мөхәммәтвәли кызы 12 бала тудыра, аларның 7 се балачагында ук фани дөньядан бакый йортка күчә[1]. Галим Гайнетдин Әхмәрев белән җәмәгате Бибисара абыстай да 12 бала тудыра, аларның да кайберләре буй җиткерә алмый якты дөнья белән хушлаша[2]. Туучыларга игътибар иткәндә, ир балалар ешрак дөньяга килгән, әмма бик иртә фани дөнья белән хушлашучылар арасында да ир балалар күпчелекне тәшкил итә. Кайбер елларны вафат булучылар саны туучылар

EV_1_08.indb 267 13.05.2008 12:20:57



1914 елгы метрикада вафат булучылар теркәлгән битләр. ТР МА, 4 ф., 180 тасв., 23 эш., 83 кгз.

саныннан артып та китә. Әлбәттә, бу ил өстенә ябырылган афәтләр белән, иң беренче чиратта, ачлык галәмәте белән бәйле. Россиядә зур ачлыклар, кызганычка каршы, шактый еш кабатланып торган. 1920-1921 елларда вафат булучылар исемлеген караганда, Идел буена ябырылган ачлыкның коточкыч булуы һәм аның татар гаиләсенә салган зур зыяны да ачык күренә. Балаларның иртә үлеменнән тыш, урта буынның да үлеме еш күзәтелә. Ир уртасы кешеләр дә, бала табу җәрәхәтләреннән 25-30 яшьлек ханымнар да гүр иясе булалар. Метрика дәфтәрләренә 55-60 яшьлек кешеләрнең үлү сәбәбен «картлыктан», дип күрсәтү дә гомер озынлыгы турында үзе үк сөйли. Шул ук вакытта, сирәк кенә булса да, йөзьяшәрләрнең дә булуы күренә[3]. Метрика язмаларындагы үлем сәбәпләренә караганда, татар җәмгыяте шул чорда киң таралган йогышлы авырулардан зыян күрә. Авыл кешесе табиб хезмәтеннән һәрчак мәхрүм булып яшәгән, шунлыктан, дәвалану турында бөтенләй сүз алып барып булмый, хәтта авыру, үлем сәбәпләре туганнары, мулла тарафыннан якынча гына билгеләнгән. Мәсәлән, иң еш очрый торган авырулардан, тир, пәри, җен зәхмәте, тиф, чәчәк авыруы, бума, ютәл, шеш, эч, баш авырулары һ. б. Күренгәнчә, авыру исемнәре гомуми мәгънәдә генә бирелә. Метрика язмаларында кечкенә яшьтәге балаларның үлем сәбәбе итеп, еш кына «әпсе» күрсәтелә. Моның нинди авыру икәнлеген төгәл генә ачыклый алганыбыз юк. Шулай да, кайбер төбәк сөйләшләрендә «әпсесе килү» — ул «күз тию» икәнлеген ишеткәнебез бар. Фаҗигале үлем очраклары да булган, шундыйлардан берсе — суга батып үлү. Татар җәмгыяте, аның әхлагы турында сөйли торган

EV_1_08.indb 268 13.05.2008 12:20:57

тагын бик үзенчәлекле нәрсә — мәрхүм турында «үтерелгән», яисә «үзенә кул салган» дигән язмаларның булмавы. Татар җәмгыятендә үтерү шикелле җинаятьләр булмый. Ислам дине дә мондый гөнаһлардан саклаган.

Татар метрика язмаларында баланың тууын теркәгәндә әтисенең дә, әнисенең дә исеме күрсәтелә. Меңләгән метрика язмаларын карап чыккан кеше буларак, татарларда никахсыз бала тудыру очраклары юк дип курыкмыйча әйтә алабыз. Бары тик бер-ике мәртәбә әтисе «намәгълүм», ягъни «билгесез» дигән язманы күрергә туры килде, әмма бер бу очрак татар җәмгыятенең торышын билгеләми, һәм ул бала никахсыз туган дигәнне дә әле расламый. Әтисенең исеме теркәлми калу бик күп сәбәпләр белән аңлатыла ала.

Туучыларның исемнәренә игътибар итсәк, XIX-XX йөз башында татарлар балаларына ислам дине белән гарәп теленнән кергән исемнәр кушканнар (Габдулла, Сәйфулла, Шәрәфетдин, Габдрахман, Фатыйма, Әсма, Әминә һ. б.). Тормышта татарлар үзара еш кына исемнәренең кыскартылган вариантларын куллансалар да, рәсми документларда, шул исәптән, метрика язмаларына да, үзләренең мулла азан әйтеп куйган исемнәрен язарга тырышканнар. Күп исемнәрнең алкушымчалары Габдел, Мөхәммәт, Әхмәт, Биби, Миңле. Бер үк кешенең исеме метрика язмаларының төрле урынында төрлечәрәк бирелергә мөмкин. Мәсәлән, Мөхәммәтвәли бер урында тутырып язылса, башка урында Вәли дип кенә дә күрсәтелә ала, хәтта Гобәйдулланың, Ибраһимның Гобәй, Ибрай дип язылу очракларын да күрергә була, әлбәттә, болар сирәк күренеш. Кайбер төбәкләрдә гарәп исемнәре белән бергә борынгы төрки-татар исемнәренең дә булуы күзәтелә. Моңа мисал итеп, хәзерге Сарман районы Алан Газар авылын күрсәтү кирәктер. Монда Асылкош, Бәхетгәрәй, Гөлҗимеш, Гөлестан кебек исемнәр очрый. Гомумән, исем бирүгә татарлар аеруча игътибар белән якын килгәннәр, исем кешене гомере буе озатып йөри торган, хәтта, кай очракта, аның язмышын да билгели торган нәрсә икәнен бик яхшы аңлаганнар. Руслардан аермалы буларак, татарлар бер үк исемне якын туганнарга, хәтта якын нәсел тармакларындагыларга да бирмәгәннәр, ләкин аларда башка үзенчәлек: вафат булган туганының исемен аннан соң туган кардәшләргә, яисә бертуганнарга да кушу бик еш очрый. Метрика язмаларын өйрәнү дәверендә, үлгән туганының исемен алган баланың да, күп вакытта, бик озак яшәмичә, барыбер вафат булуын күзәттек.

Татарларда фамилия бик озак вакыт кулланылмаган һәм аның әллә ни кирәге дә булмаган. Баланың тууын теркәгәндә, әтисе фәлән, фәлән улы дип, әнисенең исеме фәлән, фәлән кызы, дип языла. Сирәк кешеләрдә генә электән килгән фамилияләре булган, ул күбрәк сәүдәгәр, мещаннарда күзәтелә. Фамилия хаҗәте килеп туганда, Диния нәзарәте бабасының исемен фамилия итеп кулланырга тәкъдим итә[4]. Татар авылларында хәзергә кадәр фамилия белән эндәшү сирәк күренеш, фәлән кеше баласы яисә фәлән нәсел кешесе дип сөйләшүне кулайрак күрәләр.

Метрикалардагы никах һәм талак теркәү сәхифәләрендә тулы бер тере тарих ята. Диния нәзарәте карары белән ирләргә никахка керү 18 яшьтән, кызларга 16 яшьтән рөхсәт ителгән, никах мөнәсәбәтләре 80 яшь белән чикләнгән[5]. Шулай булуга да карамастан, авылларда татар кызының 18 яшьтән дә яшьрәк кияүгә бирелүе документаль яктан расланмый. Өйләнешүчеләрнең яшенә күз салсак, хатын-кызның иреннән еш кына өлкәнрәк булуы күренә, яисә алар яшьтәшләр, я булмаса, хатын-кыз 1-2 яшькә генә яшьрәк. Бу бик гади аңлатыла: авыл җирендә эш күп, һәм хатын-кыз төп эшче көчнең бер өлешен тәшкил иткән, ягъни бик яшь кызны килен итеп алу «артык кашык»

EV_1_08.indb 269 13.05.2008 12:20:57



Татар гаиләсе. Светозарная Казань: Каталог выставки. – Санкт-Петербург, 2005. – С. 116.

алу гына булып калуы ихтимал бит. Ир белән хатын арасында яшь аермасы зур булган очраклар да бар, ягъни карт кешенең 30 яшьлек ханымга өйләнүе, мондый никахларда ир белән хатын икесе дә алдагы никахларыннан тол калган кешеләр.

Гаилә кору, никахның бик җитди адым икәнлеген метрикадагы язмалар да дәлилләп тора, бу гамәл күпсанлы шаһитлар катнашында башкарылган. Төп шаһитлар һәм бу эшнең җитәкчеләре — ике якның да әтиләре, алар вәли вәкил дип аталган. Кайбер очракта мондый вазифаны бертуганнары да үтәгән. Егет үзенә үзе дә вәли вәкил була алган, ләкин кызның үзенә-үзе вәли вәкил булуы чиктән тыш сирәк хәл, бу бары тик 1917 елдан соң гына аз-маз күренгәли башлый. Бу хәл татар хатын-кызының хокукы чикләнгәнен аңлатмый. Икенче төр шаһитлар — ризалык шаһитлары, һәр ике яктан да, икешәр, ә кайбер очракта дүртәр шаһит билгеләнгән — болар туганнар, күршеләр яисә мәҗлестә булучы танышбелешләр. Шаһитларның саны күп булу — үзе үк бу гамәлнең җитдилегенә ишарә. Татар халкында гаилә кору зур адым саналганлыктан, якын туганнарының шаһитлыгыннан тыш, бер генә никах та теркәлмәгән. Никахны яшерен рәвештә уку мулланың указы алынуга сәбәп була алган, шуңа да никах өчен нинди генә киртәләр булса да, ике як бер уртак фикергә килеп, мәсьәләне хәл итәргә тырышкан. Шаһитлар никахның законлы булуын раслап, аның дөреслеге хакында үз өсләренә җаваплылык алып, имзаларын яисә тамгаларын куйганнар. Монда татарларның үз нәселенең һәр тармагы вәкилләре белән аралашып яшәве, бер-берсен бик әйбәт белүен күрергә була, никахта ризалык

EV_1_08.indb 270 13.05.2008 12:20:57


шаһитлары булып, еш кына шул нәсел тармагыннан булган кешеләр чыгыш ясаганнар. Татар кешесе һәрвакытта да үз нәселен әйбәт белгән, ерак буын туганлыгы гына булса да, аны якын иткән.

Метрика язмаларына карап, XIX-XX йөз башы татар хатын-кызларының хокуклары турында фикер йөртеп була, һәм бу документлардан аңлашылганча, татар хатын-кызы җәмгыятьнең зур хокукларга ия булган катлавын тәшкил иткән. Моңа мисал итеп, аңа никах вакытында бирелгән мәһәрне дә китерергә мөмкин. Гадәттә мәһәр малы ике өлештән торган: бер өлеше никах укыган вакытта тапшырылган, ә икенче өлеше «көтәчәк мал» дип аталган. Мәһәрне алучы фәлән кадәр мәһәрне хәзер алдым дип, ә бирүче фәлән кадәр мәһәр бирәсе калды дип имзасын куярга тиеш булган. Диния нәзарәте таләбендә «көтәчәк мәһәр хатынның ир өстендәге бурычы булып, бер тараф үлгәндә, яхуд аерылышканда ул мәһәр хатын файдасына буладыр. Авылларда мәһәр итеп ат, сыер, түшәк, ястык һәм башка шундый нәрсәләр язылса, аның кыйммәте язылып бәян ителергә тиеш. Ат, сыер төсе белән язылса яхшы булыр»[6], диелә. Мәһәр күләме өйләнүче кешенең байлыгына карап, төрлечә булган, ләкин моңа малны иркен тотарга тырышканнар, шул заманның иң зур малының берсе — ат, сыер бирү дә сирәк хәл түгел. Моннан тыш түшәк, ястык, шәл, яулык, сандык, күпмедер күләмдә акча, шул заманның тормыш хәлен исәпкә алганда, мәһәр суммасы беркайчан да аз булмаган, ягъни бу өстән бурычны төшерү өчен генә түгел, ә чын мәгънәсендә, хатын-кызны кайгыртып эшләнгән.

Аерылышу процессында да хатын-кыз мәнфәгатьләре беренче планга чыга, ислам динен тоткан, аның канунарын белгән кеше мондый чакта хатын-кызны авыр хәлгә калдыруны түгел, ә киресенчә, күпмедер гомер юлын бергә үткән кешегә хәленнән килгән кадәр җиңеллек тудырырга тырышкан. Аерылышу эшләре ир кеше һәм хатынның атасы арасында алып барыла, ә хатын бу хәлләргә турыдан-туры катнашмый, ләкин бу факт һич кенә дә, хатын-кызның бу эшләрдә хокуксыз булуын аңлатмый. Ислам тәртипләре буенча, ана булган яисә киләчәктә ана буласы хатын-кызлар һәртөрле күңелсез хәлләрдән, стресслардан мөмкин кадәр сакланылган, шуңа да, аерылышу хәлләрендә хатын-кызның барлык таләпләре әтисе аша җиткерелгән. Һәм ул һәрвакыт үзенә тиешлесен ала алган. Гамәлнең законлылыгын, аның гадел үтәлүен исә шаһитлар раслаган.

XIX-XX йөз башында талак бик сирәк күренеш, булган кадәресенең дә төгәл сәбәбен билгеләү авыр, чөнки татар кешесе күңел халәтен читләргә белдерергә ашкынып тормый. Күп очракта «арада мәхәббәт юклык сәбәпле» дип языла, ләкин Диния нәзарәте фикеренчә, нәкъ менә шушы сүзләр астында мөһим мотивлар яшереп калдырыла, аерылышуга китергән чын сәбәпләрне төгәл ачыкларга тырышу кирәк, диелә[7]. Мәсәлән, талак сәбәбе итеп, мулла болай дип яза: «Ир талак кылды, хатын талак кылмады, бик елады. Сәбәбе үзенә мәгълүмдер, безгә бәян кылмады»[8]. Татар хатын-кызы талак мәсьәләсендә дә хокуксыз булмый, ул иренең гамәлләре, үзен тотышы белән канәгать түгел икән, талак таләп итә алган. Ләкин гаиләнең мөһимлеген, бу адымның җитдилеген аңлаган татар хатыны да, ире дә юкбар сәбәпләр өчен генә бу юлны сайламаган. Шуңа да аерылышулар саны күп түгел, һәм алар да соңгы чиктә генә, мәсәлән, хатын бала таба алмаган очракта, кулланылган. Хәллерәкләре исә, бу очракта, беренче хатынны аермыйча гына, икенче хатын алырга тырышканнар. 1916-1917 елларда талаклар саны арта, димәк, илдә, җәмгыятьтә күзәтелгән тотрыксызлыклар гаиләгә дә турыдан-туры тәэсир иткән булып чыга.

EV_1_08.indb 271 13.05.2008 12:20:58



1914 елгы метрикада талак кылучылар теркәлгән битләр. ТР МА, 4 ф., 180 тасв., 23 эш., 86 кгз.

Ислам динендә рөхсәт ителгән күпхатынлылык мәсьәләсенә аерым тукталып, метрика язмалары нигезендә татар җәмгыятендә бу күренешнең хәлен аңлатырга тырышып карыйк. Татарлар арасында күпхатынлылык, әлбәттә булган, ләкин бу күренеш бер хатынлы гаиләләргә караганда азрак. Моны, бәлки «күпхатынлылык» дип түгел, ә «икехатынлылык» дип атасак дөресрәк булыр, чөнки икедән артык хатын алучылар юк дәрәҗәсендә, булган очракта да, зур байлыкка ия кешеләрдә генә күзәтелә, ә алар бу чорда татар җәмгыятенең бик аз өлешен тәшкил иткәннәр. Ике хатын алуга китергән сәбәпләрне барлаганда, алар түбәндәгеләр: беренче хатынның озак вакыт дәвамында авыруы, бала таба алмавы. Бу очракта татар хатын-кызы үз мәнфәгатьләрен генә беренче планга куймыйча, акыллы фикер йөртеп, иренә икенче хатын алуга үзе рөхсәт бирә. Ислам кануннары буенча, хатын-кыз рөхсәтеннән башка икенче никах укылу мөмкин түгеллеге мәгълүм. Тагын бер мөһим сәбәп — ир-атның туганы үлеп китсә соң, аның балаларын ятим итмәү, башка гаиләгә үги итеп җибәрмәү өчен тол калган хатынын һәм гаиләсен үз карамагына алу бурычы. Бу очракта нәсел малын бүлүне булдырмау теләге дә күпмедер роль уйнаган. Ничек кенә булмасын, ир кеше үзенең хатын-кыз алдындагы бурычын аңлап, бу гамәлне кылуга алынган. Берничә хатын алу, шактый авыр заманда ир өчен зур канәгатьләнү алып килүдән бигрәк, хатын-кызның, аның балаларының киләчәк тормышындагы тотрыклылыкны гарантияләгән. Моны ислам кануннарында каралган үзенә күрә «социаль страховка» итеп кабул итәргә кирәк.

EV_1_08.indb 272 13.05.2008 12:20:58

Татар җәмгыятенең тагын бер үзенчәлеге: татар кешесенең үз нәселен туган авылында гына дәвам итәргә тырышуы, чит авылларга күчеп яшәү, яисә хатыны авылында яшәү бөтенләй юк диярлек, бары тик муллалар гына указ белән башка авылларга, өяз-губерналарга билгеләнеп, гомерен туган авылыннан читтә үткәрергә мөмкин. Шулай да, Россиядә барган хәлләр татар гаиләсен читләтеп үтмәгән, җирсезлек, солдат хезмәте татарны сибелергә дә мәҗбүр иткән, нәсел җепләрен дә өзгән. Солдат хезмәте татар кешесе өчен авыр бер язмыш сынавы булган. Рекрутлыкка алынган кеше гомеренең зур өлешен сыек шулпа ашап үткәрүдән тыш, булган сәламәтлеген шунда калдырып, авылына гарип-гораба булып кына кайткан, яисә бөтенләй кайта алмаган. Өзелеп калган нәсел җепләре нигездә нәкъ менә шул солдат хезмәте белән бәйле дә инде.

Метрика язмалары, гомумән алганда, татар гаиләсенең, татар җәмгыятенең XIX-XX йөз башындагы торышын күпьяклап өйрәнүгә мөмкинлек тудыра, биредә сүз алып барылган моментлар моның кайбер яклары гына.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. ТР МА, 4 ф., 177 тасв., 88 эш, 141 б кгз.; 89 эш, 152 кгз.; 90 эш, 144 кгз.; 92 эш, 153 кгз., 158 кгз.; 94 эш, 169 б кгз.; 6 өстәмә тасв., 369 эш, 19 б кгз., 25 кгз., 30 б кгз., 34 кгз., 45 кгз., 50 б кгз., 74 кгз., 76 б кгз., 79 кгз., 85 кгз., 89 кгз.; 6 өстәмә тасв., 431 эш, 103 кгз.
2. РФ Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе. Архив-тикшерү эше № 2-7050. Әхмәрев Сәетгәрәй Гайнетдин улын гаепләү эше.
3. ТР МА, 4 ф., 177 тасв., 838 эш, 135 б кгз.
4. Метрика язу вә рәсми кәгазьләр йөртү хакында // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыя-и Оренбургыя. – 1916. – № 20. – Б. 13-14.
5. Шунда ук. – № 12-13. – Б. 22-27.
6. Шунда ук.
7. Шунда ук. – № 15. – Б. 7-11.
8. ТР МА, 4 ф., 177 тасв., 841 эш, 111 б кгз.

Эльмира Сәлахова,
тарих фәннәре кандидаты

РЕЗЮМЕ

В статье кандидата исторических наук Э. Салаховой рассказывается о татарской семье XIX — начала XX в. на основе сведений, содержащихся в метрических книгах.

EV_1_08.indb 273 13.05.2008 12:20:58